ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2023 Олы Кайбыч ав. № 296

Участоктан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге 13-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2023 елның 1 сентябрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында Федоровский авыл җирлеге, Федоровский авылы, Зур Кызыл ур., 2 җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы 455,1 кв.м булган 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлеген күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонада файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» (йорт янындагы) » рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Шартлы рөхсәт бирү турында карар проектындагы материаллар белән Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин.

3. Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат адресын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт

ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар һәм материаллар уздыру турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») челтәр басмасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Б.Р. Сәлаховка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина